МУНИЦИПАЛЬНОЕ КАЗЕННОЕ УЧРЕЖДЕНИЕ «УПРАВЛЕНИЕ ОБРАЗОВАНИЯ ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО КОМИТЕТА ЧИСТОПОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА» РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. К. Маркса, дом 21,
город Чистополь, 422980

«ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫНЫҢ МӘГАРИФ ИДАРӘСЕ» МУНИЦИПАЛЬ КАЗНА УЧРЕЖДЕНИЯСЕ

Карл Маркс урамы, 21 нче йорт,
Чистай шәһәре, 422980

Тел/факс: 5-10-41, 5-10-34, 5-12-97, Upravl.Obrazovaniya@tatar.ru, http://edu.tatar.ru/chistopol/roo

22.02.2018 № 258

На №________ от_________

**Татарстан Республикасы**
**Премьер-министры урынбасары**
**Татарстан Республикасы**
**Мәгариф һәм фән министры**
**Р. Т. Борһановка**

Бәяләмә

Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе ана теле һәм әдәбияты укытучыларының Бөтенроссия күләмендә үткәрелә торган “Туган тел” мастер-класс бәйгесенең республика этабына муниципаль этапта җиңү яулаган Чистай муниципаль районы МБГББУ “2 нче номерлы гимназия”сенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы Гыйльманова Сәкинә Минеһади кызын тәкъдим итә.

Гыйльманова Сәкинә Минеһади кызы, югары квалификацион категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы, 25 елдан артык хезмәтен яшь буынга белем һәм тәрбия бирүгә багышлады. Теоретик һәм методик әзерлеге, даими үсештә булуы Сәкинә Минеһади кызына педагогик эшчәнлеген югары дәрәҗәдә оештырырга мөмкинлек бирә. Укытучы“ФДББС шартларында укыту һәм тәрбия эшчәнлеген оештыруга заманча якын килү” методик темасы өстендә нәтиҗәле эшли. Бу күрсәткечләр укучыларның белем дәрәҗәсе, бәйгеләр, фәнни-гамәли конференцияләр нәтиҗәләре белән дәлилләнә.

Сәкинә Минеһади кызы укучыларны фәнни-эзләнү, иҗади эшчәнлеккә тарта. Аның укучылары яшүсмерләрнең Кояш Тимбикова исемендәге III регионара фәнни-эзләнү укуларында - призёр, Раштуа укуларында - III дәрәҗәдәге диплом, Гаяз Исхакый исемендәге республикакүләм фәнни-гамәли конференциясендә призёр булдылар. Укучыларының хезмәтләре төрле дәрәҗәдәге фәнни-гамәли конференцияләр җыентыкларында бастырылды.

Республика күләмендә үткәрелгән иҗади һәм сәнгатьле сөйләм бәйгеләрендә Сәкинә Минеһади кызының укучылары призлы урыннарны яуладылар. Мәсәлән, Г.Тукай исемендәге V һәм VI халыкара шигырь укучылар бәйгесендә, “Татар кызы–2017”, “Минута Славы” республикакүләм талантлар

конкурсында, М.Җәлилнең 110 еллыгына багышланган бәйгедә призлы урыннарга лаек булдылар.

Укытучы дәресләрен заман таләпләренә туры китереп оештыра, тәнкыйди фикерләү һәм иҗади үсеш технологияләренә нигезләнеп эшли. Һәр дәреснең методик яктан уйланылган булуы Сәкинә Минеһади кызынын тәҗрибәле мөгаллим икәнлеген раслый. Бу үз чиратында укыту сыйфатының югары булуын тәэмин итә, белем күрсәткечләре динамикасында чагыла (өлгереш 100%, белем сыйфаты 79%).

Мөгаллимә укыткан татар сыйныфы, татар һәм рус төркемнәре БРТны 100% өлгереш һәм 85 – 93% сыйфат белән бирделәр.

Сәкинә Минеһади кызы укучылары татар теле һәм әдәбияты буенча үткәрелә торган олимпиадада һәр уку елында призлы урыннар яулыйлар, ә 2017нче елда аның укучысы республика күләмендә призёр булды.

Ул гимназиядә “Хыял” драма түгәрәген җитәкли. Сәкинә Минеһади кызы укучылары К.Тинчурин театры сәхнәсендә уңышлы чыгыш ясадылар. Туфан Миңнуллин исемендәге укытучылар һәм укучыларның III һәм IV республика конференциясендә - лауреат, Кәрим Тинчурин исемендәге VI халыкара милли драматургия театр фестивалендә - II урын, “Сәйяр” балалар һәм яшүсмерләрнең республика театр фестивалендә III урынга лаек булдылар. “Сабантуй” һәм район газетасында укучыларының иҗади эшләре даими бастырылып килә.

Сәкинә Минеһади кызы мәктәп музее оештыручы да. Җәмгыятькә файдалы зур эзләнү-тикшерү эшләре алып барганы, кызыклы экспозицияләр һәм тәрбия эшендә уңышлары өчен “Мәктәп музее” таныклыгына ия булды.

Мөгаллимә даими эзләнә, үзе дә республикакүләм Р.Фәхретдин укуларында, “Татарская лингвокультурология: проблемы и перспективы”, “Жить, помня о корнях своих..” III Бөтенрәсәй “Татар теле һәм әдәбияты: бүгенгесе һәм киләчәге”, регионара “Диалог культур. Формирование российской гражданской идентичности подрастающего поколения” дип аталган фәнни-гамәли конференцияләрдә актив катнаша. КФУда “Социализация учащихся средних классов в совместном труде со взрослыми” темасы астында үткән методологик семинарда чыгыш ясап, “Мастер класс - инновацион педагогик тәҗрибәне таратуда эффектив алым” дигән темага үткәрелгән регионара семинарда мастер-класс үткәреп, эш тәҗрибәсе белән уртаклашты.

Сәкинә Минеһади кызы тарафыннан төзелгән “Милли төбәк компоненты кертеп, татар теленнән дидактик күнегүләр җыентыгы” һәм “Тел күрке – сүз” дигән электив курс программаларын район укытучылары файдалана.

Укытучының дәрес һәм сыйныфтан тыш чара үрнәкләре “Электрон мәгариф” журналларында, “Ачык дәрес” газеталарында бастырылып килә.

Тырыш хезмәте, яшь буынны укыту һәм тәрбияләүдә ирешкән уңышлары өчен:

- ике ел рәттән 2011, 2013нче елларда – “Безнең иң яхшы укытучы” республика Грантына ия булды;
- 2013нче елда “Мәгарифтәге казанышлары өчен” күкрәк билгесе белән бүләкләнде;
- “Мәгариф” журналы һәм “Сабантуй” газетасы редакциясе исеменнән рәхмәт хатлары алды.

Укытучының ижади лабораториясе бай. Кабинет интерактив укыту җайланмалары, кирәкле фәнни-методик әдәбият, электрон укыту әсбаплары, тарату материаллары белән тәэмин ителгән.

Гыйльманова С.М. педагогик эшчәнлеге һәм шәхси сыйфатлары белән башка укытучыларга үрнәк булып тора. Укытучының укучылар, ата-аналар, коллегалары белән мөнәсәбәте үзара ышаныч, бер-берсен хөрмәт итүгә нигезләнгән. Сәкинә Минеһәди кызы - сыйныф җитәкчесе буларак та бик җаваплы педагог. Мөгаллимә югары сыйфатлы белем һәм тәрбия бирү юнәлешендә максатчан, нәтиҗәле эш алып бара, һәрвакыт яңалыкка омтыла, интерактив технологияләрне өйрәнә, уңышлы куллана.

Мөгаллимә туктаусыз эзләнә, педагогик осталыгын даими камилләштерә, югары сыйфатлы белем бирү юнәлешендә максатчан һәм нәтиҗәле эш алып бара, һәрвакыт яңалыкка омтыла, интерактив технологияләрне өйрәнә, уңышлы куллана.

Чистай муниципаль районы
Мәгариф идарәсе начальнигы Г.Ә.Нәбиуллин